КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 апрель г.Казань № 406

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль ипотека системасында торак төзү өчен түләүсез бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеген раслау хакында» 2008 ел, 4 август, 559 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 23 июнь, 416 нчы, 2018 ел, 13 июль, 569 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль ипотека системасында торак төзү өчен түләүсез бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль ипотека системасында торак төзелеше өчен түләүсез бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге»;

1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 13 июль, 587 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 декабрь, 1234 нче; 2022 ел, 1 март, 189 нчы, 2023 ел, 20 февраль, 167 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибенә, 2 пунктның өченче

абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннар бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 7 март, 200 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 20 февраль, 167 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннар бирү тәртибенә, 2 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин